**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Олы Салтык авыл җирлегенең Даныш авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

14 ноябрь 2025 ел № 4

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Олы Салтык авыл җирлеге Уставының 26 статьясы нигезендә, 2025 нче елның 14 нче ноябрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: "Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Даныш торак пунктында турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, кондезге бүлектә укучы студентлардан кала, җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:
- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 55 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 27 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 27 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлеге составына керүче Даныш авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Олы Салтык авыл җирлегенең Даныш торак пунктында турыдан-туры яшәүче, яшәү урыны буенча теркәлгән, кондезге бүлектә укучы студентлардан кала, җирлек территориясендә тавыш бирү һәм түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә алынган акчаларны җибәрү хокукына ия булган һәр балигъ булган кешедән 2026 елда 500 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;
- торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү” карарын кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмати стендларда халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Олы Салтык авылы, Свердлов урамы, 126 йорт;
- ТР, Кама Тамагы районы, Даныш авылы, Кооператив урамы, 71 йорт, шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә 10(ун) көн эчендә урнаштырырга кирәк.

Халык җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы КамаТамагы
муниципаль районы Олы Салтык
авыл җирлеге башлыгы Р.М. Вафин